**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы,423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

№109 «18» декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2012 елның
28 декабрендәге «Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади
авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында» № 37 карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы № 438-ФЗ Федераль законнарга таянып Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2012 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» № 37 карарына (Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябрендәге №88; 2021 елның 16 июнендәге №30; 2021 елның 19 августындагы №33, 2022 елның 18 маендагы №62 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 42 статьясындагы 2.3 пунктының 11 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, аларны эксплуатацияләү, реклама конструкцияләрен сервитут шартларында урнаштыру һәм эксплуатацияләү максатларында автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосалар чикләрендәге җир кишәрлекләрен (шәхси автомобиль юлларыннан тыш) куллану, җир кишәрлекләрен инженер коммуникацияләрен сузу, күчерү, үзгәртеп кору, аларны сервитут шартларында эксплуатацияләү максатларында куллану.».»

1.2. 42 статьясының 2.2 пунктының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлына бүлеп бирү полосасының чикләре территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә билгеләнә, җир законнарында каралган очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе М.М.Әминов